**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
***Сарман авыл җирлеге***

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
11 ноябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында 2026 елда гражданнарның үзарасалым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 22 статьясы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Уставы нигезендә:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Сарман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы карар итә:

1.Татарстан республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Әхмәт авылы, Ленин урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әхмәт авылы клубы бинасында 2025 елның 21 нче ноябрендә сәгать 13:00 минутта Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында 2026 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар, I һәм II төркем инвалидлардан һәм хөкем ителгәннәр, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар, тормыш өчен авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр, янгыннан зыян күрүчеләрдән) тыш Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 2026 елда 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү гә ризамы:

1) Яңа Әхмәт торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү

2) Яңа Әхмәт т. п. торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

3) Яңа Әхмәт торак пунктында традицион Күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3. Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2026 елда

гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 31.10.2025 ел, № 2 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarma-novo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман авыл җирлеге Совет Рәисе

Сарман муниципаль районы Башлыгы Ф. М. Хөснуллин